СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» март 2023 ел **№ 72**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 апреленең 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 23 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:

«4) нормалаштырылмаган эш көне өчен айлык өстәмә;

5) закон нигезендә эш бирүченең аерым күрсәтмәсе белән билгеләнә торган муниципаль хезмәткәрне акчалата бирелә торган башка өстәмә түләүләр».

1.2. 31 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминиятләштерү системаларында шәхси (шәхесләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.